Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
«Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР

№ 1 03 февраль 2020 ел

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Түбән Мактама поселок Советының 2008 елның 01 декабрендәге 93/1 номерлы карары белән расланган Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар уздыру турындагы нигезләмәгә таянып.

КАРАР БИРӘМ:

1. «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге, «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге, Әлмәт муниципаль районының Яңа Нәдер авыл җирлеге территорияләре буйлап узучы «Тозлы агымлы торбаүткәргеч» объекты өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты – 2020 елның 19 феврале 9: 00 сәгатьтә.

2.2. Срок проведения - не менее одного и не более трех месяцев со дня опубликования настоящего постановления.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Некрасов ур., 18 А й.

2.4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Түбән Мактама ш.т.б., Некрасов ур., 18 А й. адресы буенча урнашкан Түбән Мактама бистә башкарма комитетына гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гаризалар бирергә

2.5. Гавами тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты-2020 елның 19 февраленә кадәр.

3. Түбән Мактама бистә башкарма комитетына (Нафикова Г.Р.) гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама бистә башкарма комитеты җитәкчесе Г.Р. Нафиковага йөкләргә.

Түбән Мактама ш.т.б. башлыгы: В.Н. Михайлов